# THE SCHOLAR AND TEACHER (ON THE 120th ANNIVERSARY OF THE BIRTH OF THE PROMINENT LINGUIST R.S.GAZIZOV)

**Gulnara Fandasovna Zamaletdinova,**
Kazan Federal University,
2 Tarastan Str., Kazan, 420008, Russia,
gulya.gali1973@mail.ru.



**GAZIZOV RIZA SALAHUTDINOVICH** (1894-1981) is a linguist. He started his pedagogical and scientific work in 1918. In 1939 he began to work as an academic secretary at the Kazan Branch of the Academy of Sciences of the USSR – the Institute of Language, Literature and History named after G.Ibrakhimov. He was wounded during World War II and came back to Kazan and worked as a researcher from 1944 to 1961. For many years he taught at KazanUniversity and the Kazan Pedagogical Institute.

He wrote scientific papers on lexicography and the comparative grammar of the Tatar and Russian languages. R. Gazizov compiled Tatar-Russian and Russian-Tatar dictionaries. He was an author of textbooks for secondary schools.

**ГАЗИЗОВ РИЗА (РИЗАЭТДИН) СӘЛӘХЕТДИН** улы (1894-1981) − тел галиме. 1918 елдан педагогик һәм фәнни-педагогик эштә. 1939 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел әдәбият һәм тарих институтында: гыйльми сәркатип, Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайткач, 1944-1961 елларда гыйльми хезмәткәр. Озак еллар Казан университетында һәм Казан педагогия институтларында укыта.

Фәнни хезмәтләре лексикографиягә, татар һәм рус телләре грамматикасын чагыштырып өйрәнүгә багышланган. Татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр төзүче. Урта мәктәпләр өчен уку әсбаплары авторы.

**ГАЗИЗОВ РИЗА САЛАХУТДИНОВИЧ** (1894-1981) − языковед. С 1918 г. в педагогической и научно-педагогической работе. С 1939 г. в Институте языка, литературы и истории Казанского филиала Академии наук СССР: ученый секретарь, после ранения, полученного в Великой Отечественной войне, и возвращения с фронта – в 1944-1961 гг. научный сотрудник. Долгие годы преподавал в Казанском университете и Казанском педагогическом институте.

Научные труды по лексикографии, сопоставительной грамматике татарского и русского языков. Составитель татарско-русских и русско-татарских словарей. Автор учебных пособий для средних школ.

August 2014 is marked as the 120th anniversary of the outstanding linguist, lexicographer and methodologist Riza Gazizov. R.Gazizov was born on August, 28 in 1894 in the village of Turay of the Mendeleyev district (Tatarstan, Russia). He received his primary education in the madrasah of his native village.

In 1906, when Riza was 11, his father, who had a conservative point of view on life, sent him to Ishmi-ishan school (the village of Tyunter, in Baltach district), which was famous in the surrounding area. Riza Gazizov was displeased with the educationand regime after three years of studying and he left for Kazan and began to

prepare to enter the most progressive educational institution of his era –the Tatar teacher's school. He went to study the Russian language with Sharafulla Akhmarov, who tutored in his house. He was enrolled in this famous educational institution in 1912 due to his diligence and persistence as well ashislearning theRussian language for three years.

After the October Revolution and the Civil war Riza Gazizov began his scientific and pedagogical activity. He taught the Russian and Tatar languages in the schools of such villages of Tatarstan as Turay (Elabuga district) and Mul'ma (Vysokogorskiy district) and he was a teacher in Tatar at the Bashkir military school, Kazan Agricultural Institute and Elabuga Pedagogical Institute. He also held the post of the inspector of the Minister of Education and for a long time he worked at Kazan filial of the USSR's Academy of Sciences – the Institute of Language, Literature and History named after G.Ibrakhimov [1: 21].

R.S.Gazizov's theoretical views about the existence and development of the Tatar language had been formed due to the works of Kayum Nasyri, an outstanding scientist, educator, historian, ethnographer and writer [2: 14]. It is necessary to include a reminder that in addition to his scientific and pedagogical activity, R.Gazizov was a person who devoted most of his life to studying different branches of Tatar linguistics, compiling dictionaries, and discovering efficient teaching methods in the Tatar and Russian languages.

His activities can be seen in several directions.

1. *The scientist's activity in compiling comparative grammar books*

R.Gazizov used pedagogical, linguistic and methodological experiences both in his tutoring and in his textbooks and methodical manuals. He wrote such fundamental works as "The Tatar language Grammar in comparison with the Russian language Grammar" (1924); "Experience in the systematical Tatar language Grammar in comparison with the Russian language Grammar" (1928, 1931, 1932), and co-authored with Mukhutdin Kurbangaliev; "Experience of the Russian language practical comparative grammar" (1939), "Experience in comparison of the grammar features of the Russian and Tatar languages" (1952), and "Comparative grammar of the Tatar and Russian languages" (1959, 1966, 1977). These works were a great contribution within the heritage of the XIX century works by scientists K.Nasiyry, V.Radlov, A.Bogoroditskiy, and M.Kurbangaliev and provided opportunities for further research [2: 4]. As he knew the Tatar and Russian languages and Russian language Grammar, R.Gazizov clearly understood the features of both languages, and this was reflected in his works. The value of this work is in his first comparative analysis of all aspects of the Tatar and Russian languages (phonetics, vocabulary and grammar (morphology and syntax). The author identifies the linguistic basics of the Native (Tatar) language and the Russian language in the educational methods in Tatar schools via his plural comparative grammars. Giving the similarities and differences in the grammatical structures and phonetic systems of the Tatar and Russian languages, he presented the differential methodology base for training in these languages with a foreign audience. His books were used as textbooks for a long time by school teachers, who trained in Russian and Tatar as foreign languages. Besides this, his thought-out and systematic works are appreciated in forming the basis of new comparative grammar books.

2. *The scientist's methodological activity*

During the 1920s and 1930s, R.Gazizov searched for new and scientifically based forms, methods and techniques, taught the Tatar language in high schools, universities and foreign audience, and wrote new textbooks and programs. The works co-authored with M.Kurbangaliev, "The manual and the textbook for Russians who learn Tatar" (1925), "The Tatar language course book for Russians" (1929), "The Tatar language textbook: for foreigners (besides Tatars)" (1931), and "The Tatar language" (for those who study without assistance) (1960), are proof of his great work done on the methodic of teaching the Tatar language for different audiences. There are some peculiarities in the textbooks and coursebooks written for the foreign audience. First, R.S. Gazizov included information about phonetics, grammar, spelling and punctuation; second, he offered a system of exercises for improving skills in understanding speech, and for retelling it in the Tatar language; third, he paid a lot of attention to working with scientific and literature material, newspapers, and magazines; fourth, he presented exercises to introduce examples of Tatar literature and new forms of working aimed at improving skills in writing of correct business documents [2: 89].

R.S.Gazizov worked hard at making programs, textbooks and educational-methodical supplies for Tatars who learned Russian. In the 1940s he wrote textbooks and manuals for primary school with the

teacher-methodologist V.M.Chistyakov. The results of this team-work were the textbooks “The Russian language (ABC-book)” (1946),“The Russian language: for the third year students (1946)” and the manual “To the teachers or the Russian language in primary Tatar school” (1949). The scientist worked alongside such methodists as I.I.Nazarov, I.I.Malkin, and school teachers M.Akhiyarova, A.Asadullin, Z.Maksudova, M.Subaeva, and E.Yahontov. Their textbooks on the Russian language were useful manuals for teachers and for students for a long time.

At the same time, R.Gazizov’s articles on training and education organization were published in the journal *Education* (*The Soviet School*). His articles “The works of drawing and applications at primary school”, “Summer work at school”, “About school exhibitions”, “The lessons of the native language due to the laboratory plan”, “Studying at primary school”, “Experience of a teacher in the integrated system of teaching two classes at the same time”, “Learning reading and writing without Hornbook through observation of the whole word”, “Studying the Russian language grammar to improve the language”, “Using the facts of the native language in learning the Russian language”, etc. were aimed at improving the education system.

The importance of Gazizov’s activity in methodics lies in considering the peculiarities of the mother tongue in teaching Russian in Tatar schools and Tatar-Russian schools as a base system, hence he made a contribution to the development of Russian-Tatar bilingualism.

3. *The scientist’s activity in lexicography*

It would be appropriate to put the academic R.S.Gazizov in first place, because of his enormous contribution to Tatar lexicography. He moved Tatar lexicography onto a new scientific level. For half a century he compiled Russian-Tatar and Tatar-Russian dictionaries,and wrote scientific articles about compiling principles. The “Russian-Tatar dictionary” published under the authorship of R.S. Gazizov, M.Kurbangaleev and I.Kuliev (1927,1932) was the first attempt at compiling a dictionary in this sphere and it was considered to be an important work at that time.

The “School Russian-Tatar dictionary” compiled alongside with scientist M.Guimadiev (1947, 1949) was an invaluable contribution and support for schools. The “Russian-Tatar dictionary” (1950) was the result of the teamwork of R.Gazizov, N.Isanbet and G.Ishmukhametova and was a pocket dictionary for readers over a long time.

The first volume of the four-volume ”Russian-Tatar dictionary” heralded R.S.Gazizov’s long work. In 1955-1959, he was a scientific editor of the first and second volumes (F.Ganiev was a scientific editor of the third and fourth volumes). R.Gazizov stayed as a leader of the team working on the dictionary till the end of the work. When compiling the dictionary he used Russian-Tatar dictionaries which had been published before the October Revolution, and in subsequent periods he used Turkic people’s dictionaries with the Russian translation, and Russian-Tatar terminological dictionaries, concerned with various fields of science. The “Russian-Tatar dictionary” compiled on the basis of D.N.Ushakov’s four-volume explanatory dictionary is considered to be the most successful work of that time. R.S.Gazizov’s article “Short grammar reference to major issues of Russian and Tatar morphology” which was published in the first volume of the dictionary, is considered a great scientific work.

In 1971 the “Russian-Tatar dictionary” containing 50,000 words was published, serving translators, publishing house editors, newspaper and magazine editors, philologists, and the general public. R.Gazizov was a scientific editor of the dictionary. R.S.Gazizov and K.S.Sabirov (letters А, Б, В, Г, Д, Е, Ж, Ќ, З, И, К, М (A, B, V, G, D, E, ZH, K (hard), Z, I, K, M,), L.T.Makhmutova (letters Л, Н, П, С (L, N, P, S), A.M.Akhunzyanov (letters О, Ф, Х, Т, П (O, F, KH, T, P), F.A.Ganiev (letter Р (R), etc., took part in compiling the dictionary.

R.S.Gazizov worked hard on the theoretical issues of lexicography concurrent with compiling dictionaries. His articles named “On the issue of the Russian-Turkish dictionarycompiling principles” (1953), “From practical work on compilingthe Russian-Tatar dictionary” (1954), “Preface to the Tatar-Russian dictionary” (1955), “Basic principles for the Russian-Tatar dictionary” (1957) and “Some questions on the lexicographical work in the Turkic republics: on putting a verb, noun and adjective in dictionaries” (1958) throw light upon the issues of compiling bilingual dictionaries. The lexicographer draws attention to the necessity of writing a grammatical reference in the dictionary and thereby he participated in the formation of the foundations of Tatar lexicography as a science.

4. *The scientist's activity in translation*

R.S.Gazizov took an interest in the translation. In the 1920s and 1930s, it was quite difficult to be in charge of such a work because of the lack of Russian-Tatar and Tatar-Russian dictionaries.

His knowledge of Tatar and Russian, comparative grammar and the peculiarities of translating made possible the translation from Russian into Tatar of the books about different spheres of people's lives. For example, Vlasov's work "Earth resources. What it gives to people?" (1926), S.Molozhaviy's pedagogical work "Methods of understanding a child" (1927), S.S.Ilyin's book "Peat riches of Tatar", etc.

In 1975 Gazizov's work was published and constantly drew attention. Gazizov translated "Anmuzazh", the work of the famous Tatar author K.Nasiyrithis, and devoted it to his 150th anniversary, changing it from Arabian into the Cyrillic alphabet and translating it into Russian. Then he compiled Arabian-Tatar-Russian dictionaries, using the term from "Anmuzazh".

Contemporaries and adherents have advised about the high methodical skills and the ample erudition of the scientist. A well-known linguist and specialist in Turkic philology F.A.Ganiev wrote about his tutor: "R.S.Gazizov had an authority among colleagues and the pedagogical public of the republic. As a talented scholar he was remarkable for being self-rigorous, hardworking, well-wishing, and friendly." [2: 8].

He died 33 years ago, in 1981. He devoted all his life, talent, and energy to his nation, his name and heritage hold a great place in the history of the science.

**References**

1. *Ganiev F.A.* Kürenekle leksikograf häm kontrastivist // Fän häm tel. 2010. №1. 20-25 bb. (in Tatar)
2. *Zamaletdinova G.F.* Rizautdin Gazizov: lingvisticheskoe i metodicheskoe nasledie. Kazan': Magarif, 2005. 135 s. (in Russian)
3. Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya shkola /Sost. M.Z.Zakiev. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 2008 . S. 60-64. (in Russian)

---

# ГАЛИМ ҺӘМ ПЕДАГОГ (КҮРЕНЕКЛЕ ТЕЛ ГАЛИМЕ Р.С.ГАЗИЗОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ)

**Гөлнара Фәндәс кызы Җамалетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420021, Казан, Татарстан ур., 2 нче йорт,
gulya.gali1973@mail.ru.

2014 елның август аенда күренекле тел галиме, лексикограф һәм методист Риза Сәләхетдин улы Газизовның тууына 120 ел тулды.

Р.С.Газизов 1894 елның 28 августында хәзерге Менделеев районы Турай авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә ала. 1906 елда әтисе 11 яшьлек Ризаны үзенең кадимилеге белән тирә-якта билгеле булган Ишми ишан мәдрәсәсенә (Балтач районы Түнтәр авылы) илтә. Өч ел «гыйлем эстәгәч», Риза Газизов, уку-укыту эшеннән һәм тәртипләрдән канәгать булмыйча, Казанга килә һәм үз чорының алдынгы уку йорты булган Татар укытучылар мәктәбенә укырга керергә әзерләнә башлый. Тырышлыгы, үҗәтлеге, һәм, өч ел буе укытучы Шәрәфулла Әхмәровның өенә йөреп, рус теленнән сабак алуы нәтиҗәсендә 1912 елда ул әлеге мәртәбәле уку йортына кабул ителә.

Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, Р.Газизов фәнни-педагогик эшчәнлеккә керешә: Алабуга өязе Турай авылы, Биектау районы Мүлмә авылы мәктәпләрендә татар һәм рус телләрен укыта, Татар-башкорт хәрби мәктәбендә, Казан авыл хуҗалыгы һәм Алабуга педагогия техникумнарында, Казан дәүләт университеты һәм Казан педагогика институтында яшь буынга белем бирә. Моннан тыш ул Мәгариф министрлыгында инспектор вазифасын башкара, озак еллар буе СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы булган Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли [1: 21].

Р.С.Газизовның татар теленең яшәеше һәм үсешенә бәйле теоретик карашлары XIX

гасырның күренекле мәгърифәтче-галиме, тарихчы, этнограф һәм язучы Каюм Насыйри хезмәтләре аша формалаша [2: 14]. Шунысын искәртеп китү мөһим: Р.Газизов, фәнни-педагогик эшчәнлек белән беррәттән, гомеренең күп өлешен татар тел гыйлеменең төрле тармакларын өйрәнүгә, сүзлекләр төзү эшенә, татар һәм рус телләрен укыту методикасы үсешенә биргән шәхес. Аның эшчәнлеген берничә юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин.

*1. Галимнең чагыштырма грамматикалар төзү өлкәсендәге эшчәнлеге.*

Р.Газизов үзе яшәгән чорга кадәр тупланган педагогик һәм лингвометодик тәҗрибәне дәреслекләрендә һәм методик ярдәмлекләрендә куллана һәм үстерә. Галимнең Мөхетдин Корбангалиев белән берлектә язылган «Грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» (1924), «Опыт систематической грамматики татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» (1928, 1931, 1932), шулай ук үз авторлыгындагы «Опыт практической сравнительной грамматики русского языка» (1939), «Опыт сопоставительного освещения грамматических особенностей русского и татарского языков» (1952), «Сопоставительная грамматика татарского и русского языков» (1959, 1966, 1977) кебек фундаменталь хезмәтләре XIX гасырның бөек галимнәре К.Насыйри, В.В.Радлов, В.А.Богородицкий, М.Х.Корбангалиевлар нигез салган традицияләрнең дәвам ителүе һәм тагын да тирәнрәк өйрәнелүе турында сөйли [2: 4]. Р.С.Газизовның татар һәм рус телләрен камил белүе, ике телнең дә үзенчәлекләрен тирән аңлавы атап кителгән хезмәтләрдә ачык чагыла. Хезмәтләренең кыйммәте шунда: ул беренчеләрдән булып татар һәм рус телләренең барлык өлкәләренә (фонетика, лексика, грамматика (морфология, синтаксис) чагыштырма анализ ясый. Күпсанлы чагыштырма грамматикалары аша автор татар мәктәбендә ана теле һәм рус теле укыту методикасының лингвистик нигезләрен билгели. Татар һәм рус телләренең аваз системасында һәм грамматик төзелешендә охшаш һәм аермалы якларны күрсәтеп, бу телләрне чит аудиториядә укытуның дифференциаль методикасына нигез сала. Шуңа күрә аның чагыштырма грамматикалары татар һәм рус телләрен чит тел буларак укыткан укытучылар өчен озак еллар буе дәреслек буларак кулланылып килде. Моннан тыш, бу хезмәтләр яңа буын чагыштырма грамматикалар өчен яхшы уйланылган, системалаштырылган ныклы нигез буларак та әһәмиятле.

*2. Галимнең методик эшчәнлеге.*

XX гасырның 20-30 нчы еллары – Р.Газизов эшчәнлегендә чит аудиториягә һәм югары уку йортларында белем алучыларга татар телен өйрәтүдә яңа, фәнни нигезле формалар, метод һәм алымнар эзләү, дәреслекләр һәм программалар төзү чоры. М.Корбангалиев белән берлектә язылган «Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» (1925), «Руслар өчен татар теле дәреслеге» (1929), «Татар теле дәреслеге: Татарлардан башкалар өчен» (1931), «Татарский язык» (для самостоятельно изучающих) (1960) методик әсбаплары төрле аудиториядә татар телен укыту методикасы өлкәсендә зур хезмәт куелганлыгын раслый. Чит аудитория өчен чыккан дәреслекләрнең үзенчәлеге түбәндәгедән гыйбарәт. Беренчедән, галим аларга фонетика, грамматика, орфография һәм пунктуациягә караган мәгълүматларны кертә. Икенчедән, телдән сөйләмне аңлау һәм үз фикерләреңне татар телендә хикәяләү күнекмәләре булдыруга күнегүләр системасын тәкъдим итә. Өченчедән, фәнни-популяр әдәбият, газет, журнал материаллары белән эшләүгә зур игътибар бирә. Дүртенчедән, татар әдәбияты үрнәкләре белән таныштыруга, гади эш кәгазьләрен дөрес язу күнекмәләре булдыруга юнәлтелгән эш төрләре кертелә [2: 89].

Р.Газизов татарларга рус телен укыту буенча күпсанлы программалар, дәреслекләр, укыту-методик әсбаплар төзү өлкәсендә дә күп эшли. XX гасырның 40 нчы елларында ул танылган укытучы-методист В.М.Чистяков белән берлектә башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр яза. Аларның хезмәттәшлек нәтиҗәсе булып «Русский язык (Букварь)» (1946), «Русский язык: для третьего года обучения» (1946) дәреслекләре, «В помощь учителю русского языка в начальных классах татарской школы» (1949) ярдәмлеге дөнья күрә. Галимнең шулай ук методистлар И.И.Назаров, И.И.Малкин, А.Ш.Әсәдуллин, мәктәп укытучылары М.Әхиярова, З.Мәксүдова, М.Субаева, Е.Яхонтовалар белән автордашлыкта чыккан рус теле дәреслекләре укучылар һәм укытучылар өчен файдалы әсбап булып, озак еллар үз кыйммәтләрен югалтмадылар [3: 61].

Моннан тыш, Р.Газизовның укыту һәм тәрбия эшләрен оештыру мәсьәләләрен яктырткан язмалары «Мәгариф» («Совет мәктәбе») журналы битләрендә даими рәвештә басылып килә. Аның «Беренче баскыч мәктәпләрдә рәсем һәм ябыштыру эшләре», «Мәктәптә җәйге эшләр», «Мәктәп күргәзмәләре турында», «Лаборатория планы буенча ана теле дәресләре», «Беренче баскыч мәктәптә уку», «Бер укытучының бер үк вакытта ике сыйныф белән комплекслы система буенча укыту тәҗрибәсе», «Бөтен сүзләр ысулы белән әлифбасыз укырга, язарга өйрәтү», «Рус теле грамматикасын өйрәнүне тел үстерү белән бәйләү», «Рус телен өйрәнүдә ана теле фактларыннан файдалану» һ.б. күпсанлы мәкаләләре уку-укыту системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Р.С.Газизовның методика өлкәсендәге эшчәнлегенең әһәмияте шунда: ул татар мәктәбендә рус телен, рус мәктәбендә татар телен укытканда, ана теле үзенчәлекләрен истә тотуның тулы бер системасын тәкъдим итә һәм шул рәвешле рус-татар икетеллеге үсешенә зур йогынты ясый.

3. *Галимнең лексикография өлкәсендәге эшчәнлеге.*

Татар лексикографиясе мәсьәләләрен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрне атаган вакытта беренче урынга, һичшиксез, Р.Газизовны кую дөрес булыр. Бу өлкәдә галимнең казанышы булып татар лексикографиясен фәнни дәрәҗәгә күтәрүе тора. Ул ярты гасыр дәвамында татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә, сүзлекләр төзү принципларына карата фикерләрен белдереп, фәнни мәкаләләр яза.

Р.Газизов, М.Корбангалиев һәм И.Кулиев авторлыгында чыккан «Татарча-урысча сүзлек» (1927, 1932) бу өлкәдә беренче тәҗрибә була һәм үз чоры өчен шактый әһәмиятле хезмәт буларак карала.

Галимнең М.Гыймадиев белән берлектә төзелгән «Школьный русско-татарский словарь» (1947, 1949) мәктәпләр өчен бәяләп бетергесез зур ярдәмлек булса, Н.Исәнбәт, Г.Ишмөхәммәтов белән язылган «Татарча-русча сүзлек» (1950) киң катлау укучылар өчен өстәл китабы буларак озак еллар хезмәт итә.

1955 елда чыккан дүрттомлык «Русча-татарча сүзлек»нең беренче томы лексикограф Р.Газизовның күпьеллык хезмәт җимеше булып тора. 1955-1959 елларда ул I һәм II томнарның фәнни мөхәррире була (III-IV томнарның фәнни мөхәррире Ф.Ганиев) һәм эшнең ахырына чаклы сүзлек коллективы белән җитәкчелек итә. Сүзлекне төзегәндә, Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соңгы чорда чыккан русча-татарча сүзлекләр, башка төрки халыкларның русчага тәрҗемә сүзлекләре, төрле өлкәләргә караган русча-татарча терминологик сүзлекләр файдаланыла. Әлеге сүзлек Д.Н.Ушаковның дүрттомлык аңлатмалы сүзлеге нигезендә төзелә һәм үз чорының иң уңышлы хезмәтләреннән санала. Беренче томда Р.С.Газизовның «Краткий грамматический справочник по основным вопросам морфологии русского и татарского языков» дигән исем астында мәкаләсе бирелә. Әлеге кереш сүз зур фәнни хезмәт булып санала [1: 23].

1971 елда тәрҗемәчеләргә, нәшрият хезмәткәрләренә, газет-журнал редакцияләренә, филологларга һәм киң катлау укучыга адресланган, 50 мең сүзне туплаган бертомлы «Русча-татарча сүзлек» дөнья күрә. Р.С.Газизов аның фәнни мөхәррире була. Сүзлекне төзүдә Р.С.Газизов һәм К.С.Сабиров (А, Б, В, Г, Д, Е, Ж, Ќ, З, И, К, М хәрефләре), Л.Т.Мәхмүтова (Л, Н, П, С хәрефләре), Ә.М.Ахунҗанов (О, Ф, Х, Т, П хәрефләре), Ф.А.Ганиев (Р хәрефе) һ.б. катнаша.

Сүзлекләр төзү белән беррәттән, Р.С.Газизов лексикографиянең теоретик мәсьәләләрен тикшерүгә дә үзенең саллы өлешен кертә. Аның «К вопросу о принципах составления русско-тюркских словарей» (1953), «Из практики работы над составлением русско-татарского словаря» (1954), «Предисловие к татарско-русскому словарю» (1955), «Основные принципы составления русско-татарского словаря» (1957) и «Некоторые вопросы лексикографической работы в тюркоязычных республиках: О подаче в словарях глагола, имени существительного и имени прилагательного» (1958) кебек мәкаләләре ике тел сүзлекләрен төзү мәсьәләләрен теоретик яктыртуга багышлана. Лексикограф сүзлек эчендә грамматик белешмә төзү кирәклегенә басым ясый һәм шул рәвешле татар лексикографиясенең фәнни нигезләрен формалаштыруда да катнаша [2: 55].

4. *Галимнең тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге.*

Р.С.Газизов тәрҗемә эше белән дә кызыксына. XX гасырның 20-30 нчы елларында мондый эшчәнлекне алып бару шактый катлаулы була, чөнки русча-татарча, татарча-

русча сүзлекләр булмый дип әйтерлек. Рус һәм татар телләрен, чагыштырма грамматиканы, тәрҗемә итү алымнарын яхшы белүе Р.Газизовка халык хуҗалыгының төрле өлкәләренә караган китапларны рус теленнән татарчага тәрҗемә ясарга ярдәм итә. Әйтик, М. һәм П.Власовларның «Җир байлыклары. Алар кешегә нәрсә бирә?» (1926), С.Моложавыйның «Баланы өйрәнү методлары» (1927) педагогик хезмәте, С.С.Ильинның «Татариянең торф байлыгы» (1935) брошюралары һ.б. әнә шундыйлардан.

1975 елда Р.С.Газизовның игътибарга лаеклы тагын бер хезмәте чыга. Ул К.Насыйриның 150 еллык юбилее уңаеннан мәгърифәтче галимнең «Әнмүзәҗ» хезмәтен гарәп графикасыннан кириллицага күчерә һәм рус теленә тәрҗемә итә, монда кулланылган терминнарның гарәпчә-татарча-русча сүзлекчәсен төзи [2: 24].

Замандашлары, шәкертләре галимнең киң эрудициясе, югары методик осталыгы турында сокланып сөйлиләр. «Р.С.Газизов хезмәттәшләре һәм республиканың педагогик җәмәгатьчелеге арасында зур авторитетка ия иде. Талантлы галим үз-үзенә таләпчән булуы, гаҗәеп хезмәт сөючәнлеге һәм башкаларга карата яхшы мөнәсәбәттә булуы белән аерылып тора иде», – дип яза үзенең остазы турында танылган тел галиме һәм тюрколог Ф.А.Ганиев [2: 8].

Р.С.Газизовның вафатына да инде 33 ел (1981) булды. Үзенең бөтен көчен, сәләтен фәнгә һәм милләтебезгә армый-талмый хезмәт итүгә багышлаган галимнең исеме һәм мирасы фән тарихында хаклы рәвештә мактаулы һәм хөрмәтле урынны алды.

**Әдәбият**


1. *Ганиев Ф.А.* Күренекле лексикограф һәм контрастивист // Фән һәм тел. 2010. №1. Б. 20-25.
2. *Замалетдинова Г.Ф.* Ризаутдин Газизов: лингвистическое и методическое наследие. Казань: Магариф, 2005. 135 с.
3. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская школа / Сост. М.З.Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. С. 60-64.